СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2021 г. Заинск № 47

**«Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе
дәүләт урман фонды җирләренә,
физик һәм юридик затларның хосусый
милкендәге җирләргә керми торган яшел
үсентеләрне кисү тәртибе турында
нигезләмәне раслау хакында»
2021 елның 03 мартындагы 32 номерлы
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 03 мартындагы 32 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1. 1 абзацта «Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 15 статьясына, Россия Федерациясе Урман кодексына, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп

эшләнгән, ул Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибен билгели» дигән сүзләрне “Әлеге нигезләмә халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 15 статьясына, Россия Федерациясе Урман кодексына, "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп эшләнгән һәм ул Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне (утыртмаларны) кисү тәртибен билгели» сүзләренә алмаштырырга.

1. 2. 3.5 пунктта «Эшләр башкаруга рөхсәт алган очракта, үз мәнфәгатьләрендә яшел үсентеләрне кисүче мөрәҗәгать итүче әлеге нигезләмә нигезендә яшел үсентеләрне кискән өчен түләүләр кертергә яки компенсация рәвешендә яшелләндерүне раслаучы документларны тапшырырга тиеш.» дигән сүзләрне «Эшләр башкаруга рөхсәт алган очракта, үз мәнфәгатьләрендә яшел үсентеләрне кисүче мөрәҗәгать итүче әлеге нигезләмә нигезендә яшел үсентеләрне кискән өчен түләү кертергә һәм (яки) компенсация рәвешендә яшелләндерү үткәрүне раслаучы документларны тапшырырга тиеш.»

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй шәһәре Советының экология һәм ТКХ мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Р.В.Әгъләмов) йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
«18»06.2021 ел
47 номерлы карарына
1 кушымта

**Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре милкендәге, өченче затлар хокукыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә алып торуга һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Мөлкәтнең исеме | Бинаның гомуми мәйданы, кв.м | Урнашу урыны, адресы | Бинаның билгеләнеше/җир кишәрлегенең категориясе | Бинаның/ җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге белән гараж | 73,4 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, «Энергетик-2» г/ш, №168 | Торак булмаган бина/торак пункт җирләре | 16:48:070104:2546 / 16:48:070104:13 |
| 2 | Җир кишәрлеге белән гараж | 144 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, «Энергетик-2» г/ш | Торак булмаган бина/торак пункт җирләре | 16:19:070104:2582 / 16:48:070104:14 |